**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2021 елның 16 июле № 52 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлегенең
генераль планын раслау турында

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 28.04.2020 ел, № 18 карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, 11.05.2021 елдагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең генераль планын расларга (1 нче кушымта ).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Официальный Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм авыл җирлекләре советлары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы Ютазы
районы Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин